СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БУРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Татарское Бурнашево _______________

2015 елның « 03» мартыннан № 57-282

КАРАР

Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен муниципаль районның җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә

Югары Ослан муниципаль районының

Бурнаш авыл җирлеге Советы

карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Советының Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитетына җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Югары Ослан муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары вәкаләтләрен тапшыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

- җир кишәрлекләре белән эш итү, дәүләт милке чикләнмәгән һәм тиешле авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү.

2. Югары Ослан муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге башкарма комитетына кабул иткән

очракта:әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне муниципаль район Башкарма комитеты белән тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында бюджет законнары нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Советының 2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләү һәм карауга тапшыру.

3. Карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору  Бурнаш авыл җирлегенең  хокук тәртибе һәм регламенты буенча советның  даими комиссиясен йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары,

Югары Ослан муниципаль районының

Бурнаш авыл җирлеге башлыгы урынбасары С.И.Андреева